ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

пр. Строителей, д.12, г. Нижнекамск, 423570

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

18 06 2021 г. № 609

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының аерым муниципаль хокукый актларына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль законның 7 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2016 елның 19 декабрендәге 433-ФЗ номерлы һәм «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 30 декабрендәге 509-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, карар бирәм:

1. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының аерым муниципаль хокукый актларына кертелә торган кушымта итеп бирелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Л.Р. Әхмәтовка йөкләргә.

Җитәкче А.Г. Сәйфетдинов

Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
Башкарма комитетының
2021 елның 18 нче июнь
609 нчы номерлы карары белән расланган
кушымта

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының аерым муниципаль хокукый актларына кертелә торган үзгәрешләр

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының түбәндәге муниципаль хокукый актларына үзгәрешләр кертергә:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 28 маенда кабул ителгән 804 номерлы карары белән расланган Чернобыль АЭС авариясе аркасында радиация йогынтысына дучар ителгән гражданнарга торак урыны алу өчен субсидияләр бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында (4 нче кушымта); Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 28 маенда кабул ителгән 804 номерлы карары белән расланган муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентында (10 нчы кушымта); Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 7 декабрендә кабул ителгән 1031 номерлы карары белән расланган «Мәктәпкәчә белем бирү буенча төп гомуми белем бирү программасын (балалар бакчалары) тормышка ашыручы мәгариф учреждениеләренә (оешмаларга) балаларны исәпкә кую һәм кабул итү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында; Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 22 мартында кабул ителгән 248 номерлы карары белән расланган Түбән Кама муниципаль районы авыл җирлекләре тарафыннан җир эшләрен башкаруга ордер бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында; Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 5 декабрендә кабул ителгән 1027 номерлы карары белән расланган индивидуаль торак төзелеше яисә бакча йорты объекты параметрларының планлаштырыла торган төзү турындагы хәбәрнамәдә күрсәтелгән билгеләнгән параметрларга туры килүе һәм җир кишәрлегендә индивидуаль торак төзелеше яисә бакча йорты объектын урнаштыру мөмкинлеге турында яисә индивидуаль торак төзелеше яисә бакча йорты объекты параметрларының планлаштырыла торган төзү турындагы хәбәрнамәдә күрсәтелгән билгеләнгән параметрларга туры килмәве һәм (яки) җир кишәрлегендә индивидуаль торак төзелеше яисә бакча йорты объектын урнаштыру мөмкинлеге булмау турында хәбәрнамә җибәрү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында; Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 14 маенда кабул ителгән 291 номерлы карары белән расланган Түбән Кама муниципаль районы авыл җирлекләре тарафыннан нотариаль гамәлләр кылу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында; Татарстан Республикасы Түбән Кама

муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 28 маенда кабул ителгән 804 номерлы карары белән расланган муниципаль лотерея уздыруга рөхсәт бирү һәм муниципаль кызыксындыру лотереясе үткәрү турында хәбәрнамәне карау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында (20 нче кушымта); Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 28 сентябрендә кабул ителгән 733 номерлы карары белән расланган каты коммуналь калдыклар туплау урынын (мәйданын) төзүне килештерү һәм каты коммуналь калдыклар туплау урыны (мәйданы) турында белешмәләрне каты коммуналь калдыклар туплау урыннары (мәйданчыклары) реестрына кертү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында; Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 7 сентябрендә кабул ителгән 634 номерлы карары белән расланган законсыз рәвештә саклаган яки табылган коралны, хәрби припасларны, коралга патроннарны, шартлаткыч җайланмалар һәм шартлаткыч матдәләрне үз теләге белән тапшырган өчен акча түләүгә реестрга кертү турында карар кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында; Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 17 гыйнварында кабул ителгән 8 номерлы карары белән расланган яңа кушымта итеп бирелә торган редакциядә урынны торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында; Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 28 маенда кабул ителгән 804 номерлы карары белән расланган ваклап сату базарын оештыру хокукына рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында (21 нче кушымта); Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 28 маенда кабул ителгән 804 номерлы карары белән расланган муниципаль берәмлек чикләрендә тулысынча яисә өлешчә җирле әһәмияттәге юллар буенча уза торган маршрутлар буенча авыр йөкләр, зур габаритлы йөкләр ташуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында (23 нче кушымта); Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 28 маенда кабул ителгән 804 номерлы карары белән расланган ана (гаилә) капиталы акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган индивидуаль торак төзелеше объектын төзү (реконструкцияләү) буенча төп эшләр башкаруны раслаучы документ бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында (63 нче кушымта); Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 28 маенда кабул ителгән 804 номерлы карары белән расланган инженерлык челтәрләре һәм коммуникацияләр трассалары схемасын килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында (19 нчы кушымта); Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 11 мартында кабул ителгән 119 номерлы карары белән расланган төзелгән яки үзгәртеп корылган индивидуаль торак төзелеше яисә бакча йорты объектының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар таләпләренә туры килүе (туры килмәве) турында хәбәрнамә җибәрү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында; Татарстан

Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 27 ноябрендәге 733 номерлы карары белән расланган тышкы мәгълүмат чараларын (паспортларны) урнаштыру проектын килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында; Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 27 октябрендәге 830 номерлы карары белән расланган җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын әзерләү һәм бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү буенча административ регламентында; Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 21 июлендәге 1204 номерлы карары белән расланган «Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыру» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында; Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 10 февралендәге 106 номерлы карары белән расланган реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында; Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 20 апрелендәге 268 номерлы карары (1-4 кушымталар) белән расланган архив эше өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентында; Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 11 февралендәге 51 номерлы (1-20 нче кушымталар) белән расланган опека һәм попечительлек өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентында; Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 31 августындагы 621 номерлы карары белән расланган Түбән Кама муниципаль районы авыл җирлекләре тарафыннан белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында:

1.1. 1 бүлекне түбәндәге эчтәлекле текст белән тулыландырырга: «Мәгълүмати технологияләрдән файдаланып, мондый хезмәт күрсәтү процедураларын автоматлаштыруны тәэмин итүче муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларының машина укый ала торган тасвирламасы мәгълүмат технологияләре өлкәсендә норматив-хокукый җайга салуны гамәлгә ашыруга вәкаләтле башкарма хакимиятнең федераль органы тарафыннан билгеләнгән таләпләр нигезендә билгеләнә.».

1.2. 3 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 3.0 пункт өстәргә:

«3.0. Гомуми билгеләр белән берләштерелгән аерым категория мөрәҗәгать итүчеләргә әлеге хезмәтләрне күрсәтү тәртибен үз эченә алган, шул исәптән аны алу өчен мөрәҗәгать иткән муниципаль хезмәт нәтиҗәсенә карата муниципаль хезмәт күрсәтү вариантлары, мөрәҗәгать итүченең муниципаль хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итү ысулына бәйле рәвештә, 2.15 пункты белән һәм әлеге бүлек белән билгеләнгән.».

2. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 11 февралендәге 51 номерлы карары белән расланган опека һәм попечительлек өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларында:

2.1. 2.5 пунктының 5 пунктчасы 18, 20 нче кушымталарын, 2.5 пунктының 4 пунктчасы 16, 17 нче кушымталарын, 2.5 пунктының 3 пунктчасы 7, 14 нче

кушымталарын, 2.5 пунктының 4 пунктчасы 11 нче кушымтасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Граждан хәле актларын теркәү органнары яки Россия Федерациясе консуллык учреждениеләре тарафыннан бирелгән уллыкка алу турында таныклыкның күчермәсе (булган очракта)»;

2.2. 2.5 пунктының 5 пунктчасы 14 нче кушымтасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Ата-аналар баланың исемен һәм (яки) фамилиясен үзгәртүне сорауга бәйле сәбәпләрне раслаучы документларның күчермәләре, атап әйткәндә, чит дәүләтнең компетентлы органнары тарафыннан бирелгән граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу турында таныклыкның күчермәсе һәм аларның нотариаль расланган рус теленә тәрҗемәсе;»;

2.3. 2.5 пунктының 6 пунктчасы 16 нчы кушымтасында «Хезмәт кенәгәсе күчермәсе» сүзләреннән соң «(2020 елның 1 гыйнварына кадәрге чорларда)» сүзләрен өстәргә;

2.4. 2.5 пунктындагы барлык кушымталарга да түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында түбәндәге документлар (белешмәләр) алына:

1) Гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу турында Гражданлык хәле актларын теркәүнең бердәм дәүләт реестрыннан белешмәләр».